Раслыйм:
49 нчы “Гөлназ” балалар
бакчасы мөдире
_______ Габидуллина Э.С.
«_21_» _____05_____ 2024 ел

# 2023– 2024 уку елының жәйге сәламәтләндерү чорына эш планы

**Максат:**

- балаларның шәхси мөмкинлекләрен исәпкә алып милли, әхлакый һәм физик яктан үстерү һәм ныгыту, тормыш куркынычсызлыгын саклау, жәйге чорны нәтиҗәле итеп үткәрү өчен шартлар тудыру.

**Бурычлар:**

- Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, авырулар һәм травматизмны булдырмау, балаларда сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга кызыксыну уяту;
- балаларны чыныктыру, сәламәтлекләрен ныгыту өчен шартлар тудыру;
- куркынычсызлык күнекмәләрен үтәүне, юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнүне камилләштерү;
- балаларның жәйге ялын оештыру мәсьәләсендә ата-аналар белән эшне оештыру;
- яңа килүче балаларның адаптация чорын яхшы үтүенә шартлар тудыру.

## 1. Гомуми оештыру эшләре

| № | Үткәреләсе чаралар | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| **Оештыру эшләре** | | | |
| 1 | Уку елы буенча белем-тәрбия бирү эшенә анализ | 31.05 га кадәр | Б/бакчасы мөдире |
| 2 | Җәй аенда бакчага йөриячәк балаларның исемлеген ачыклау | Майның 3-4 атнасы | тәрбиячеләр |
| 3 | Җәйге сәламәтләндерү чорына план һәм белем бирү челтәрен төзү, раслау | 31.05 га кадәр | Өлкән тәрбияче, б/бакчасы мөдире |
| 4 | Инструктаж үткәрү:<br>- балаларның тормышын һәм иминлеген, сәламәтлеген саклауны оештыру;<br>- техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү;<br>- травматизмны булдырмау.<br>- сәламәтләндерү һәм табигый чыныктыру чаралары; | Июнь-август | Б/бакчасы мөдире, завхоз,<br>өлкән шәфкать туташлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - йогышлы эчәк авырулары һәм аңа каршы көрәш. | | |
| 5 | Җәйге чорга календарь план төзү | Җәй дәвамында | Тәрбиячеләр |
| 6 | Физкультурадан диагностика нәтиҗәләре буенча коррекцион эш планы төзү | 31.05.2024 кадәр | Тәрбиячеләр, физинструктор |
| 7 | Уеннар, шөгыльләр, бәйрәм һәм күңел ачу чаралары, консультацияләр һәм экскурсияләр оештыру. ЮЙК (ПДД), янгын куркынычсызлыгы (ПБ), СЯР (ЗОЖ), ТИК (ОБЖ) һ.б. буенча әңгәмәләр, тематик чаралар планлаштыру. | Җәйге план нигезендә | Белгечләр, тәрбиячеләр |
| 8 | Травматизмны булдырмау өчен шартлар тудыру | Җәй дәвамында | Б/бакчасы мөдире, завхоз, ш/туташлары |
| 9 | Җәйге чорда эшләү өчен методик кулланмалар һәм әдәбият белән тәэмин итү | Җәй дәвамында | Өлкән тәрбияче |
| 10 | Җәйге чорда физкультура-сәламәтләндерү һәм сәламәтлекне ныгыту чараларын оештыру | Һәркөнне | Тәрбиячеләр, өлкән шәфкать туташлары |
| 11 | Әңгәмәләр:<br>- «Җәйге чорда физкультура-сәламәтләндерү эшен оештыру»,<br>- «Җәйге чорда балаларга беренче медицина ярдәме күрсәтү»,<br>- «Инфекцион чирләрне булдырмау чаралары»,<br>- «Җәйге чорда балаларны чыныктыру»<br>- «Яшелчә түтәлен һәм чәчәк клумбаларын тәрбияләүгә балаларны тарту» | Июнь-август | физинструктор<br>шәфкать туташы<br>шәфкать туташы<br>шәфкать туташы<br>өлкән тәрбияче |
| 12 | Җәйге чорга мәйданчыкта сәламәтлек сукмагын (тропа здоровья) булдыру | 01.06.2024 кадәр | Тәрбиячеләр, өлкән шәфкать туташлары |
| 13 | Төркемнәр арасында ярыш:<br>- «Иң матур мәйданчык»,<br>- «Иң матур чәчәк түтәле», | Ай саен | Өлкән тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - «Иң яхшы яшелчә түтәле» | | |
| **Административ-хуҗалык эшләре** | | | |
| 1 | Җәйге чорга әзерлекне, МАФларның торышын, тормыш иминлеге һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренең үтәлешен комиссия белән тикшерү | 20-31.05. 2024 | Б/бакчасы мөдире, завхоз, өлкән тәрбияче |
| 2 | Территорияне төзекләндерү: МАФлар, комлыклар, верандаларны өлешчә ремонтлау һәм буяу. | Җәй дәвамында | завхоз |
| 3 | Агач-куакларны, яшелчә түтәлен, клумбаларны тәртипкә китерү, тәртиптә тоту | Җәй дәвамында | завхоз |
| 4 | Материаль-техник базаны ныгыту | Җәй дәвамында | Б/бакчасы мөдире |
| 5 | Комлыкларның, верандаларның торышына, урын-җирне алыштыру графигының үтәлешенә контроль | Даими | өлкән ш/туташлары |
| 6 | Мәйданчыкларның һәм МАФларның торышы буенча контроль | Һәркөнне | өлкән ш/туташы, завхоз |
| 7 | Комлыкларга, түтәлләргә су сибү, верандаларның юылышы | Даими | өлкән ш/туташы |
| 8 | Бакча территориясенең һәм мәйданчыкларның чисталыгын тикшерү | Җәй дәвамында | Завхоз, ш/туташы, өлкән тәрбияче |
| 9 | Яңа уку елына балалар бакчасын хәзерләү | Август | Б/бакчасы коллективы |

## 2. Сәламәтләндерү эше

***2.1. Төркемнәрдә сәламәтлекне ныгыту чараларының вакытлары***

| Вакыты | Сәламәтлекне ныгыту чараларының эчтәлеге | Җаваплы |
|---|---|---|
| **6.00-7.00** | Төркемне җилләтү | Тәрбиячеләр, өлкән ш/туташлары |
| **7.45-8.10** | Саф һавада иртәнге гимнастика (барлык төркемнәрдә) | Тәрбиячеләр, физинструктор |
| **8.20- 8.45** | Гигиена чаралары (иртәнге аштан соң) | Тәрбиячеләр |
| **9.00.00-11.30** | Саф һавада булу; хәрәкәтле уеннар оештыру; комнан, үләннән, җирдән яланаяк йөрү. Җиңелчә киемнән саф һавада мөмкин кадәр күбрәк булу. Су белән уеннар. Кояш һәм һава ванналары алу. ЛФК һәм сулыш гимнастикасы элементларын кулланып, физкультура шөгыльләре уздыру | Тәрбиячеләр, белгечләр, ш/туташлары |
| **11.30-12.00** | Аяк юу, аякларны контраст коендыру (кояшлы көннәрдә) | Тәрбиячеләр, өлкән ш/туташлары |
| **12.00-12.30** | Тозлы су белән тамак чайкау (зур төркемнәрдә көндезге аштан соң) | Тәрбиячеләр, өлкән ш/туташлары |
| **15.00-15.15** | Гимнастика, массажлы келәмнән йөрү. Уртанчылар, зурлар төркемнәре сырлы тактадан йөрү | Тәрбиячеләр, өлкән ш/туташы |
| **15.15-15.20** | Һава процедуралары | Тәрбиячеләр, өлкән ш/туташы |
| **15.40-16.15**<br>**17.00-18.00** | Саф һавага чыгу | Тәрбиячеләр |

*2.2 Сандезрежимны үтәү чаралары*

| № | Эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| **1. Коллектив белән эш** | | | |
| 1 | Консультацияләр уздыру :<br>- «Кояшта кызыну һәрвакыт файдалымы?»;<br>- «Күзләрне кояштан саклыйк»;<br>- «Балалар организмын чыныктыру системасы (Су, һава һәм кояшны рациональ куллану)»;<br>- «Эчәк авыруларын кисәтү»;<br>- «Талпаннан саклану чаралары». | Июнь-август | өлкән ш/туташы |
| 2 | Иртәнге фильтр үткәрүгә, сандезрежимның үтәлешен контрольдә тоту | Июнь-август | өлкән ш/туташы |
| 3 | Балаларны һәм хезмәткәрләрне тире авыруларына һәм беткә карауны уздыру | Июнь-август | өлкән ш/туташы |
| 4 | Урам уенчыкларын юу | Көн саен | Тәрбиячеләр, өлкән ш/туташы |
| 5 | Төркемнәрдә урын-җирнең һәм сөлгеләрнең маркировкаларын контрольдә тоту | Көн саен | Тәрбиячеләр |
| 6 | Эпид.ситуациягә карап инструктажлар үткәрү | Җәй айлары | өлкән ш/туташы |
| **2. Балалар белән эш** | | | |
| 1 | Балалар белән әңгәмәләр:<br>- «Ни өчен кулларны юарга кирәк?»<br>- «Җиләк-җимешак булыгыз»<br>- «Сулыкларда уйнау - куркыныч»<br>- «Сәламәтлек кагыйдәләре» | Июнь-август | өлкән ш/туташы |
| 2 | Төрле чыныктыру чараларын куллану | Даими | өлкән ш/туташы |
| 3 | Хәрәкәт активлыгын көчәйтү | Даими | өлкән ш/туташы |
| 4 | Куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту | Даими | өлкән ш/туташы |
| **3. Ата-аналар белән эш** | | | |
| 1 | Травматизмны кисәтү буенча стенд булдыру: «Травматизмны булдырмау чаралары» | июнь | өлкән ш/туташы |
| 2 | Төркемнәрдә стенгазета чыгару «Җәйне файдалы үткәрик» | Июль | өлкән ш/туташы, тәрбиячеләр |
| 3 | Сәламәтлек почмакларында мәгълүматлар булдыру: | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - «Баланы дәвалауга караганда, авыруны булдырмау һәм чыныктыру җиңелрәк»;<br>- «Талпаннан сак булыгыз!»<br>- «Белгеч киңәшләре»;<br>- «Сәламәт яшәү рәвеше» - буклетлар тарату;<br>- «Юылмаган куллар, яшелчә, җиләк-җимеш – инфекция чыганагы». | Июнь-август | өлкән ш/туташы, өлкән тәрбияче |

## *2.3 Чыныктыру чаралары*

| № | Чаралар | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Яңа килгән балаларның адаптациясен күзәтү. Ата-аналар, педагоглар белән консультация үткәрү. | Һәркөнне | тәрбиячеләр, педагог-психолог, өлкән ш/туташы, өлкән тәрбияче |
| 2 | Балаларны мәйданчыкта кабул итү, иртәнге гимнастика | Һәркөнне | тәрбиячеләр, физинструктор |
| 3 | Су эчү режимын саклау, кояш һәм эссе сугуны булдырмау | Һәркөнне | өлкән ш/туташы, тәрбиячеләр, тәрбияче ярдәмчеләре |
| 4 | Хәрәкәт режимын һәм көндәлек режимны, саф һавада булу режимын саклауны контрольдә тоту | Һәркөнне | өлкән ш/туташы, өлкән тәрбияче |
| 5 | ЛФК, сулыш гимнастикасы элементларын кулланып, музыка һәм физкультура шөгыльләрен саф һавада уздыру (сколиоз, яссытабанлылык, салкын тиюләрдән профилактика) | Шөгыльләр челтәре буенча | өлкән ш/туташы, тәрбиячеләр, музыка һәм физкультура җитәкчеләре |
| 6 | Яссытабанлылыкны булдырмау максатыннан комнан, таштан, үләннән яланаяк йөрү | Җәй буе | тәрбиячеләр |
| 7 | Кояш һәм һава ванналары алу | Җәй буе | ш/туташы, тәрбиячеләр |
| 8 | Көндезге йокы алдыннан аякларны юу | Һәркөнне | өлкән ш/туташы, тәрбиячеләр |
| 9 | Көндәлек режимда шәхси эш алып бару | Һәркөнне | тәрбиячеләр |
| 10 | Хәрәкәтле уеннар оештыру | Һәркөнне | Тәрбиячеләр |
| 11 | Консультацияләр:<br>- «Агулы үсемлекләрдән сак булыгыз»<br>- «Сандезрежимны үтәү»;<br>-«Балада ашказаны-эчәк авыруларын кисәтү»;<br>-«Кояш сугуны булдырмау»;<br>- «Кечкенәләр төркемендә адаптация чоры». | Июнь-август | өлкән ш/туташы |
| 12 | Ата-аналар почмагында тематик мәгълүматлар булдыру | август | өлкән ш/туташы |
| 13 | Кулларны терсәккә кадәр салкынча су белән юу. Ашаганнан соң авызларны кайнаган су белән чайкау | Җәй буе Һәркөнне | өлкән ш/туташы, тәрбиячеләр |
| 14 | Көнгә 1 тапкыр тамакны тозлы су белән чайкау | Һәркөнне | өлкән ш/туташы, тәрбиячеләр |

## 3. Балалар белән айлык эшләрнең перспектив планы

| Эчтәлек | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|
| **ИЮНЬ** | | |
| **1 атна, тема *«Балаларны яклау» атналыгы***<br>- 1 июнь – балаларны яклау көне<br>- «Дуслар нинди була?<br>- «Баланың хокуклары һәм бурычлары»<br>- «Кешелеклелек сыйфатларын бала чактан тәрбияләргә кирәк»<br>**- «Бәхетле балачак» асфальтта рәсем күргәзмәсе - *(күңел ачу чарасы)*** | 31.05<br>03.06-07.06 | Тәрбиячеләр, белгечләр |
| **2 атна, тема *«Җәйге маҗаралар»***<br>– «Ни өчен җәйне яратасың?» - әңгәмә<br>- «Йолаларны һәм традицияләрне бергәләп саклыйк»<br>– «Авылларда гөрли сабантуйлар» - сабантуй турында сөйләшү<br>- ***«Сабантуй» (күңел ачу чарасы)*** | 10.06-14.06 | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчеләре, белгечләр |
| **3 атна, тема *«Яшь галимнәр» атналыгы***<br>– «Кошлар, кортлар, бөҗәкләрнең файдасы» - күзәтүләр турында сөйләшү<br>– «Тәҗрибәләр көне» (төрле тәҗрибәләр үткәрү)<br>– Эзләнүләр-тикшерүләр уздыру (табигатьтә күзәтү, тикшеренү, тәҗрибәләр үткәрү)<br>– Табигый байлыклар һәм аларның әһәмияте турында сөйләшү<br>– ***«Галимнәр тәҗрибә уздыра» күңел ачу чарасы*** | 17.06-21.06 | Тәрбиячеләр, белгечләр |
| **4 атна, тема *«Юл билгеләрен онытмыйк» атналыгы***<br>– «Юл йөрү кагыйдәләрен үтибез»<br>– «Бала – иң мөһим пассажир!» әңгәмәләр<br>– «Юлда йөрү уен түгел» - уеннар көне<br>– Асфальтта рәсем күргәзмәсе<br>- ***«Юлда булсаң, уяу бул!» (күңел ачу чарасы)*** | 24.06-28.06 | Тәрбиячеләр, белгечләр |

| ИЮЛЬ | | |
|---|---|---|
| **1 атна,** ***тема «Туган ягым җәе» атналыгы***<br>- «Әй, ямьле җәй, ямьле җәй!» җәйдәге үзгәрешләрне күзәтү, әңгәмә<br>- «Җиләкле җәй» рәсем күргәзмәсе<br>- «Туган ягым – яшел бишек» әңгәмә<br>- Җәй турында әкият, хикәяләр уку<br>- ***«Әй, ямьле җәй!» (уеннар белән күңел ачу чарасы)*** | 01.07-05.07 | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчеләре, белгечләр |
| **2 атна, тема** ***«Яшь талантлар»***<br>– «Нәрсә ул талант?» әңгәмә<br>– «Без спектакль куябыз» әсәрләрне сәхнәләштереп уйнау<br>– «Театрда» сюжетлы-рольле уеннар<br>– «Балалар дөньясы – әкият»<br>- ***«Яшь талантлар үсә» (балалар көче белән концерт кую)*** | 08.07-12.07 | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчеләре, белгечләр |
| **3 атна, тема** ***«Су» атналыгы***<br>– «Яңгыр ничек барлыкка килә?» кызыклы мәгълүматлар белән танышу<br>– Су әйләнеше турында әңгәмә<br>– Су һәм табигатьтәге күренешләр турында табышмаклар<br>– Су һәм сабын куыгы белән тәҗрибәләр уздыру<br>– ***«Нептун көне» бәйрәме*** | 15.07-19.07 | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчеләре, белгечләр |
| **4 атна, тема** ***«Сәяхәтчеләр көне»***<br>– Карта һәм глобуслар көне<br>– «Нәрсә? Кайда? Кайчан? Нигә?» сораулар көне<br>– «Халыкара дуслык» көне<br>– Яшь эзләнүчеләр көне<br>– ***«Әйдәгез сәяхәткә!» (күңел ачу чаралары)*** | 22.07-26.07 | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчеләре, белгечләр |
| **5 атна, тема** ***«Әкият дөньясы» атналыгы***<br>– Әкиятләр, төрле маҗаралар турында сөйләшү<br>– «Яраткан әкият герое» асфальтта рәсемнәр ясау<br>– Хәрәкәтле уеннар уйнау<br>- «Татар халык әкиятләре» көне<br>– ***Әкиятләр дөньясына кунакка» (әкиятләр уку көне)*** | 29.07 – 02.08 | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчеләре, белгечләр |

| **АВГУСТ** | | |
|---|---|---|
| **1 атна, тема *«Бергәләп чыныгабыз» атналыгы***<br>– «Витамин кайда үсә?» дөрес туклану серләре турында сөйләшү<br>– «Безнең сәламәт буласы килә» хәрәкәтле уеннар уйнау<br>– Чисталык турында әңгәмә<br>– «Әйдәгез, зарядкага!» спорт уеннары<br>– ***«Сәламәт тәндә-сәламәт акыл» (спорт уеннары, бәйгеләр, эстафеталар)***<br>– | 05.08-09.08 | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчеләре, белгечләр |
| **2 атна, тема *«ЮЙК атналыгы»***<br>- Юл йөрү кагыйдәләре турында сөйләшү<br>- «Җәяүлеме, шофермы, юл кагыйдәсен сакла» (ЮЙКн ни өчен сакларга кирәклеге турында әңгәмә)<br>- «Җәяүлеләр һәм пассажирлар көне» (үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында әңгәмә)<br>- «Юл уяулык сорый» - ситуацияләр уйнау<br>- ***«Иминлек безнең кулларда» (юл йөрү кагыйдәләре буенча күңел ачу чарасы)*** | 12.08-16.08 | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчеләре, белгечләр |
| **3 атна, тема *«Яхшы эшләр» атналыгы***<br>– «Яхшы булу кыенмы?» әңгәмә<br>– «Хезмәте барның хөрмәте бар» әңгәмә<br>– «Халык авыз иҗаты» көне (мәкаль-әйтемнәр әйтү)<br>– «Олыларны олы ит, кечеләрне кече ит»<br>- ***«Яхшылык җирдә ятмый» (күңел ачу чарасы)*** | 19.08-23.08 | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчеләре, белгечләр |
| **4 атна, тема *«Туган ягым-гөлләр иле»***<br>– Туган як турында әңгәмә<br>– «Туган ягым – гөлләр иле» (туган як табигатен рәсемдә төшерү)<br>– Чәчәк бәйрәменә ата-аналар белән бару<br>– «Республика буйлап сәяхәт» презентация карау<br>- ***«Туган көнең белән, Татарстан!» (күңел ачу чарасы)*** | 26.08-30.08. | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчеләре, белгечләр |

## 4. Ата-аналар белән эш

| № | Эчтәлек | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | **Ата-аналар өчен консультацияләр:**<br>- «Уен аша сөйләм телен үстерәбез»<br>- «Сәламәт яшәү рәвешен үзебездән башлыйк»<br>- «Баланы бакчага әзерләү ата-ананың бурычы»<br>- «Хәрәкәттә - бәрәкәт» | июнь-август | өлкән ш/туташлары, педагог – психолог, физинструктор, татар теле тәрбиячеләре |
| 3. | Ата-аналар соравы буенча индивидуаль һәм төркемләп консультацияләр уздыру | Җәй буе | Тәрбиячеләр, педагог-психолог |
| 5. | Сәламәтлек почмакларында мәгълүматлар булдыру:<br>- «Инфекция авыруларын булдырмау һәм алардан саклану чаралары»<br>- «Суалчан авырулары һәм аңа каршы көрәш»<br>- «Кояш сугудан сак булыгыз!»<br>- «Талпаннан сакланыгыз!»<br>- «Бетләүне булдырмау чаралары»<br>- «Бала белән табигать кочагында»<br>- «Баланың сәламәтлеге сезнең кулда, әти-әниләр!» | Июнь-август | Педагоглар |
| 7. | «Хезмәт десанты» - ата-аналарны мәйданчыкларга, яшелчә, чәчәк түтәленә эшкә тарту | Июнь - август | тәрбиячеләр |
| 8. | Бәйрәм һәм күңел ачу чараларын бергәләп уздыру | Атнага 1 тапкыр | Тәрбиячеләр, белгечләр |

## 5. Милли белем бирү эшчәнлеге

| № | Эчтәлек | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Музейны экспонатлар белән тулыландыру | Җәй дәвамында | Рус теле тәрбиячесе |
| 2 | ТР һәм РФ халкының традицияләре, мәдәнияты һәм көнкүреше белән таныштыру буенча бәйрәм һәм күңел ачу чараларын оештыру һәм үткәрү:<br>– «1 июнь-балаларны яклау көне»<br>– «Сабантуй»;<br>– «Милли йолаларны бергәләп саклыйбыз»<br>– «Без театр куябыз»<br>– «Мин яратам сине, Татарстан» | 3 июнь<br>14 июнь<br>июнь – август<br><br>август | Рус теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| 3 | Ата-аналар өчен тематик стенд әзерләү:<br>– «Милләтебезнең киләчәге безнең балаларда»<br>– «Татарстан - туган җирем» | Җәй дәвамында | Тәрбиячеләр |

## 6. Методик эшләр

| № | Эчтәлек | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Яңа педагогик әдәбият һәм матбугат белән таныштыру | Ай саен | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 2 | УМК материалларын җәйге чорда куллану | План буенча | Барлык педагоглар |
| 3 | Җәйге чорда танып-белү эшчәнлеген оештыру | июнь-август | Тәрбиячеләр |